
Балалар – урмандагы «җәнлекләр»: «төлкеләр», «куяннар», «аюлар», «бүреләр», алар төркемнәргә бүленеп, бүлмәнең төрле җирләренә урнашалар. Аучының кулында ике кечкенә туп. Ул урманда җәнлекләрне караштырып йөри һәм, берникадәр йөргәч, ял итәргә утыра. Шулвакыт тәрбияче: «Куяннар, төлкеләр чыктылар», – ди. Бу сүзләрне ишетүгә, үз исемнәре әйтелгән җәнлекләр өннәреннән чыгалар (балалар аларның характерлы кыланышларын күрсәтеп йөриләр. Мәсәлән, куяннар ике аякта сикерәләр, төлкеләр койрыкларын болгап йөриләр. Тәрбияче: «Аучы!» – диюгә, барлык җәнлекләр өннәренә таба йөгерәләр, ә аучы аларны «ата» – тупларны бер-бер арт- лы ыргыта. Туплар кемгә дә булса тисә, шуны, алып китеп, «читлеккә» (билгеләнгән урынга) утырта. Аучы 3–4 җәнлекне аткач, яңа «аучы» сайлана, уен яңадан башлана.

***Бергәләп өйрәник***



# ***Исәнме, Яңа ел!***

## ***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

## ***(4-5 яшь)***

## Табышмаклар

*Үзе кардай ап-ак ул,
Озын колак бик сак ул.
Дошман күрсә элдертә,
Кем аны куып җитә?
 (Куян)
* Ул өстенә җәй дә, кыш та
Энәле күлмәк кия.
Шулай да аны әнкәсе
«Йомшагым» диеп сөя.
 (Керпе)
* Асрамый да умарта,
 Балны бик, бик ярата.
Кышын сөя йокыны,
Язгача тормый ята. (Аю)
* Үзе ялагай,
Үзе хәйләкәр.
Ул нәрсә булыр,
Йә, әйтеп җибәр. (Төлке)
* Сорыдыр төсе,
Үткендер теше,
Урманда йөри,
Бозаулар күзли. (Бүре)

## *Кыш бабай*

Җилкәсенә капчык асып,
Кыш бабай килеп керде.
Төрле кызык сүзләр әйтеп, Бүләк
өләшеп йөрде.

Аннан Кыш бабайтыпырдап,
Бик шәп бии башлады.
Биемәскә, аягында —
Безнең апа башмагы.
Мәрзия Фәйзуллина

## Һай, Кыш бабай

Кемнең кигән киемнәре
Кем соң безгә шундый ямьле
Энҗе кар бөртекләре? Яңа ел
алып килә? Кемнең көмеш күк
сакалы,
Матур-матур капчыкларга
Чәчләре, керфекләре?
Күчтәнәч салып килә?
Ә дигәнче үсте бабай —
Үзебездән дә биек.
Эчкә сыймый шатлыгыбыз —
Киттек тирәли биеп.
Чаңгы-чанада шуарга
Булды шома тавыбыз.
Кем безгә аны ясаган,
Кем икән ул, табыгыз...
*Җәвад Тәрҗеманов*

## Куышу

Уен мәйданчыгының каршы якларына ике туры сызыла. Болар – балаларның «өйләре». Барлык балалар бер туры сызыкның артына (өй эченә) басалар. Турылар арасында уйнаучыларның берсе басып тора. Өй эчендә торучы балалар түбәндәге сүзләрне әйтәләр: Без, балалар, яратабыз йөгереп, сикереп уйнарга. Әйдә, безне куып кара, Көчеңҗитсә тотарга, Тот! Тәрбияченең «Бер, ике, өч, инде монда көч!» дигән сүзеннән соң барысы да, өйдән чыгып, каршыдагы өйгә йөгерәләр. Ике өй арасындагы бала йөгерүче балаларны тота. 2–3 бала тотылганнан соң, икенче тотучы сайлана, һәм уен яңадан башлана.

## *Аучы һәм ерткыч җәнлекләр*

Уйнаучылар арасыннан бер бала «аучы» итеп билгеләнә. Ул бүлмәнең бер почмагында тора.